ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 16.01.2023 **КАРАР**

21

Алабуга муниципаль районы территориясендә
социаль челтәрләр мониторингы төркеме
«Алабуга муниципаль районының
Кибердружинасы» төзү турында

Халыкның билгеле бер категорияләренә юнәлдерелгән, шулай ук террорчылыкка каршы тору концепциясе нигезендә террорчылыкны, экстремизмны, милләтчелекне профилактикалауны эшләү мәсьәләләрен хәл итү, җинаятьчел контентның Интернет челтәрендә басылып чыгуын профилактикалауга мәгълүмати-пропаганда алып бару максатыннан, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 28 декабрендәге Пр-2665 номерлы Указы белән расланган 2019-2023 елларга Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы торуның комплекслы планы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрьендәге «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» ярдәмче программасы, Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия утырышының 2020 елның 4 августындагы ПР-166 номерлы беркетмәсенең 1.19 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы территориясендә «Алабуга муниципаль районының Кибердружинасы» социаль челтәрләре мониторингы төркемен төзергә.
2. «Алабуга муниципаль районының Кибердружинасы» социаль челтәрләр мониторингы төркеме составын расларга (1 нче кушымта).
3. «Алабуга муниципаль районының Кибердружинасы» социаль челтәрләр мониторингы төркеме турында Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

Документ создан в электронной форме. № 21 от 16.01.2023. Исполнитель: Мусина Е.А.
Страница 1 из 9. Страница создана: 17.01.2023 15:43
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче | ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ | Л.Ф. Нургаянов

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA

Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович

Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
16.01.2023
21
номерлы
карарына 1 нче кушымта

**«Алабуга муниципаль районының Кибердружинасы»**

**социаль челтәрләр мониторингы төркеме составын**

**составы**

Төркем җитәкчесе:
Липатов Максим Николаевич - Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Барс» яшьләр үзәге» МБУ директоры;

Төркем әгъзалары:
1. Суриков Алексей Павлович -
ТР АМР «1 нче спорт мәктәбе» МБУ чаңгы ярышлары тренеры;
2. Якшевич Татьяна Олеговна -
ТР АМР «1 нче спорт мәктәбе» МБУ методисты;
3. Михайлова Татьяна Владимировна -
ТР АМР «Олимп» спорт мәктәбе» МБУ методисты;
4. Пупышев Анатолий Аркадьевич -
ТР АМР «Юность» спорт мәктәбе» МБУ өстәл теннисы буенча тренер;
5. Хәбибуллина Елена Николаевна –
Алабуга медицина училищесының информатика укытучысы (килешү буенча);
6. Сөнгатуллин Ранис Шәүкәт улы-
ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Алабуга Үзәк дини оешмасы мөхтәсибәте (килешү буенча);
7. Епанешников Роман Владимирович –
«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Барс» яшьләр үзәге» МБУ яшьләр белән эшләүче белгеч;
8. Алехин Артем Юрьевич –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Барс» яшьләр үзәге» МБУ җәмәгатьчелек белән элемтә итүче белгеч;
9. Носырева Венера Сергеевна –
«Яшь десантник» аерымланган структур бүлекчәсе мөдире;
10. Серов Владислав Сергеевич –
укытучы, Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте тулай торагы тәрбиячесе (килешү буенча);
11. Иванова Елена Михайловна –

информатика укытучысы, «Алабуга политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе, җаваплы зат (килешү буенча);

12. Меховых Ольга Викторовна –
Алабуга муниципаль районының «И.И. Шишкин исемендәге 1 нче балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе ;

13. Ачинцева Елена Николаевна -
Алабуга муниципаль районының «2 нче балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

14. Арбачакова Екатерина Николаевна –
Алабуга муниципаль районының «А.Т. Гәрәев исемендәге 2 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

15. Панькова Ирина Андреевна –
«Ә. Бакиров исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

16. Гесс Екатерина Михайловна –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

17. Вәгыйзова Лаүзә Гыйлембаян кызы –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «1 нче гимназия» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

18. Чижик Ксения Павловна –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

19. Мансурова Маргарита Витальевна –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «2 нче гимназия» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

20. Полуйко Наталия Геннадьевна –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

21. Дранкова Юлия Юрьевна –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «4 нче гимназия» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

22. Кочнева Елена Валентиновна –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе»» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

23. Костина Ольга Владимировна –
«Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 7 нче санлы Алабуга мәктәбе» белем бирү дәүләт бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары (килешү буенча);

24. Филиппов Андрей Александрович –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

25. Шабурова Регина Рамил кызы –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «9 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе»» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

26. Павлова Елена Юрьевна –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

27. Габитова Римма Зөфәр кызы –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Алабуга мәктәп-интернаты» гомуми белем бирү дәүләт бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары (килешү буенча);

28. Кошкина Алиса Илфат кызы –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Полилингваль белем бирү комплексы «Адымнар - Алабуга» гомуми муниципаль автономияле белем учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

29. Лобанова Елена Александровна –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «11 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эше буенча директор урынбасары;

30. Галиева Ләйсән Хатип кызы –
«Морт урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эше буенча директор урынбасары;

31. Чувашова Евгения Павловна -
«Бехтерево урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эше буенча директор урынбасары;

32. Клинова Алена Анатольевна –
«Танайка урта белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эше буенча директор урынбасары;

33. Жаркова Лилия Өлфәт кызы –
«Поспелово урта белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эше буенча директор урынбасары;

34. Миросанова Валентина Васильевна –
«Олы Шүрнәк урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

35. Сафина Земфира Камил кызы –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Лекарево урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

36. Николаева Елена Ивановна –

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе «Яковлево урта белем бирү мәктәбе» тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

37. Юнусова Зөлфәт Ясәви кызы –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Иске Юраш урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эше буенча директор урынбасары;

38. Шәйдуллина Фидания Равил кызы –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Костенеево урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эше буенча директор урынбасары;

39. Корнева Надежда Николаевна –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Иске Күклек төп белем бирү мәктәбе» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары;

40. Харченко Ксенья Геннадьевна –
Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Мурзиха башлангыч мәктәп - балалар бакчасы» гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе директоры;

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
20___ елның ___ _ номерлы

16.01.2023
21
карарына 2 нче кушымта

**«Алабуга муниципаль районының Кибердружинасы»**
**социаль челтәрләр мониторингы төркеме турында Нигезләмә**

1. «Алабуга муниципаль районының Кибердружинасы» социаль челтәрләр мониторингы төркеме гражданнарның интернет челтәрендә эшләүче ирекле берләшмәсе булып тора. Ул, экстремизмны профилактикалау һәм террорчылыкка каршы тору максатыннан, интернет челтәрендә хокук бозуларны күзәтеп барырга һәм алар турында хокук саклау органнарына хәбәр итәргә әзер булган ирекчеләрне берләштерә.

2. «Алабуга муниципаль районының Кибердружинасы» социаль челтәрләр мониторингы төркеме үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте, башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары һәм күрсәтмәләренә, шулай ук әлеге нигезләмәгә таяна.

3. «Алабуга муниципаль районының Кибердружинасы» социаль челтәрләр мониторингы төркеменең төп бурычы булып түбәндәгеләр тора:

а) Интернет челтәрендә «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясы таләпләрен боза торган мәгълүматны, шул исәптән түбәндәге мәгълүматны урнаштыруны тикшереп тору:

- балаларны аларның гомеренә һәм (яки) сәламәтлегенә куркыныч тудыручы, шул исәптән үз сәламәтлегенә зыян салуга, үз-үзенә кул салуга китерүче гамәлләр кылуга этәрүче;
- балаларда наркотик чаралар, психотроп һәм (яки) аңын томалый торган матдәләр, тәмәке әйберләре, алкоголь һәм спиртлы продукция, сыра һәм аның нигезендә җитештерелә торган эчемлекләр куллану, комарлы уеннарда катнашу, сукбайлык яки теләнчелек белән шөгыльләнү теләге уятырга сәләтле;
- көч куллану һәм (яки) рәхимсезлек мөмкинлеген яисә кешеләргә яки хайваннарга карата көч куллану гамәлләрен кулланулы нигезли яки аклый торган, күрсәтелгән Федераль законда каралган очраклардан тыш;

б) террорчылык һәм экстремизм күренешләрен кисәтү һәм интернет челтәрендә куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча гамәлләрне яраштыруга ирешү максатында, Алабуга муниципаль районы яшьләр оешмаларының хокук саклау органнары белән эшчәнлеген координацияләү;

в) Алабуга муниципаль районында террорчылыкка һәм экстремизмга каршы торуга юнәлтелгән чараларны планлаштыру һәм гамәлгә ашыру.

4. «Кибердружина» түбәндәгеләргә хокуклы:

- үз компетенциясе кысаларында интернет челтәрендә террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру өчен кирәкле карарлар кабул итәргә;
- дәүләт, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле документларны, материалларны, һәм мәгълүматны соратып алырга;
- Кибердружина эшендә катнашу өчен җирле үзидарә органнары, оешмалар (аларның җитәкчеләре белән килештереп) һәм ата-аналар җәмәгатьчелеге вәкилләрен җәлеп итәргә;
- Киберджина компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

5. «Кибердружина» җитәкчесе:

- «Кибердружина» эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;
- Кибердружина кабул иткән карарларга имза куя;
- Кибердружина компетенциясенә кергән мәсьәләләрне тиз арада карау кирәк булганда, киңәшмәләр үткәрү турында карарлар кабул итә;
- Киберджина карарлары үтәлешен контрольдә тота;
- ай саен эшче төркем әгъзаларыннан мәгълүмат җыя һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе секретаренә гомумиләштерелгән мәгълүмат тапшыра.

6. Кибердружина әгъзалары түбәндәгеләргә бурычлы:

- Кибердружина киңәшмәләрендә катнашырга, карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышуда һәм алар буенча карарлар эшләүдә катнашырга;
- киңәшмәдә катнашу мөмкин булмаган очракта (ашыгыч очракта), бу турыда Кибердружина җитәкчесенә алдан хәбәр итәргә;
- Кибердружина карарлары үтәлешен контрольдә тотуда катнашырга;
- кирәк булган очракта, Кибердружина җитәкчесенә көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча үз фикерләрен язмача юлларга;
- интернет челтәрендә деструктив төркемнәрне/сайтларны мониторинглау буенча башкарылган эшләр турында ай саен язмача хисап юлларга.